СОВЕТ СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.09.2018 с.Соболевское 55-224

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге Карар проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2017елның 16 октябрендәге 145 номерлы карары нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами тыңлаулар уздыру юлы белән проектны тикшерүдә катнашуга хокукларын үтәү максатларында,

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проектын 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе 2 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе 3 нче кушымта нигезендә.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Татарстан Республикасы Югары Ослан районының Соболевский авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча халык алдында тыңлауларны 2018 елның 11 октябрендә 15 сәгатьтә авыл мәдәният йорты бинасында, Соболевский авылы, Береговая урамы, 54 йорт адресы буенча уздырырга.

4. Башкарма комитетка Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегендә яшәүчеләрнең кергән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Советына карауга кертергә.

5. 2018 елның 10 сентябренә кадәр әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Соболевский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районының
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О. Н. Майорова